| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **с. Тюлячи** | **КАРАР** |
| **«21» июнь 2023г.** | | **№ 99** |

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 17 мартындагы 25 номерлы «Торак биналарны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану, торак бинаны торак булмаган бинага, торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, торак йортлардагы торак һәм торак булмаган биналарны үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче районы прокуратурасының 2023 елның 16 маендагы № Исорг-20920037-337-23/-20920037 номерлы протестын карап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 сентябрендәге 1708 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 17 мартындагы 25 номерлы «Торак биналарны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану, торак бинаны торак булмаган бинага, торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, торак йортлардагы торак һәм торак булмаган биналарны үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» карарына (2018 елның 26 июнендәге 391 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) исемдә «Торак биналарны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану, торак бинаны торак булмаган бинага, торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, торак йортлардагы торак һәм торак булмаган биналарны үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» сүзләрен «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия төзү турында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «Торак биналарны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану, торак бинаны торак булмаган бинага, торак булмаган бинаны торак бинага күчерү, торак йортлардагы торак һәм торак булмаган биналарны үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзергә» сүзләрен «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия төзергә» сүзләренә алмаштырырга.

Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәдә:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә»;

б) 1.1 пунктта:

- «Бинаны торак бина, Торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында Нигезләмәне раслау турында» сүзләрен «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәне раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

- «, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты» сүзләре белән тулыландырырга;

в) 1.2 пунктта «Бинаны торак бина, Торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында Нигезләмәне раслау турында» сүзләрен «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәне раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

г) II бүлектә:

- икенче абзацны «, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты» сүзләре белән тулыландырырга;

- өченче абзацны «яисә реконструкцияләүгә» сүзләреннән соң «, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты» сүзләре белән тулыландырырга;

д) III бүлекнең 4 абзацында «, бакча йортының» сүзләрен өстәргә;

е) 4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, ләкин кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла. Комиссиянең чираттагы утырышын уздыру

турында карарны комиссиягә кергән бина хуҗалары, бәяләнә торган милеккә, хокук иясенә яки гражданга (эшкә алучыга) карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы гаризаларын исәпкә алып комиссия рәисе кабул итә, яки Дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарының аларның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча бәяләмәсе нигезендә, торак бинаны экспертизалау нәтиҗәсе нигезендә, әлеге экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 21 августындагы 1082 номерлы «Иректе иминиятләү механизмын файдаланып, иминият хисабына зыянны каплау һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бюджет чаралары хисабына тапшырыла торган ярдәм хисабына Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан гражданнарның торак урыннарына китерелгән зыянны каплауны оештыру программасы кысаларында каплауга каралган зыянның күләмен билгеләү методикасын, иректе иминиятләү механизмын файдаланып, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан гражданнарның торак урыннарына китерелгән зыянны каплауны оештыру программасы кысаларында китерелгән каплауга каралган зыян китерелгән торак урынга экспертиза үткәрү Кагыйдәләрен раслау турындагы, һәм урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә үткәрелгән, яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан формалаштырылган һәм расланган күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан алынган, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган региональ ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларын, гадәттән тыш хәл зонасы чикләрендә урнашкан объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлеген (алга таба - объектларның (торак биналар) җыелма исемлеге) кулланып алынган мәгълүматлар нигезендә.

Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлегенә кертелмәгән торак урынының милекчесе, хокук иясе яисә яллаучысы комиссиягә әлеге пунктның беренче абзацында каралган гариза бирергә хокуклы.»;

ж) 4.3 пунктта «Бинаны торак бина, Торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында Нигезләмә белән» сүзләрен «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмә белән» сүзләренә алмаштырырга;

з) 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Күпфатирлы йортның яшәү өчен яраклылыгы (яраксызлыгы) турындагы мәсьәләне карау һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану өчен гариза бирүче торак урыны урнашкан урын буенча комиссиягә, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган, Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмә нигезендә каралган документларны тапшыра»;

и) 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Эш нәтиҗәләре буенча комиссия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган, Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә биналарның һәм күпфатирлы йортларның туры килүен бәяләү турында түбәндәге карарларның берсен кабул итә: бинаның торак бинага куелган таләпләргә туры килүе һәм аның яшәү өчен яраклылыгы турында; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган, Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәдә билгеләнгән торак бинаның эксплуатация процессында югалтылган характеристикаларын китерү максатыннан бинаны капиталь ремонтлауга, реконструкцияләүгә яки үзгәртеп планлаштыруга (кирәк булганда техник-икътисади нигезләмә белән) тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында; бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында; күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында; күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану өчен нигезләрне ачыклау турында; күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигезләр булмау, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында.»;

к) 4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Бәяләмә барлык документлар белән бергә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитетының тиешле карар (боерык) проектын әзерләү өчен, тапшырылырга тиеш. Алынган нәтиҗә нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты нәтиҗә алынган көннән алып 30 календарь көн эчендә, ә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән торак биналарны тикшергән очракта, - нәтиҗә алынган көннән алып 10 календарь көн дәвамында билгеләнгән тәртиптә биналарны торак биналар, торак биналарны гражданнарга яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты, шулай ук күпфатирлы йортларны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында Карар кабул итә (Россия Федерациясе Торак фонды һәм күпфатирлы йортлардан тыш, Федераль милектә булган), һәм бинаны алга таба куллану,

йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган очракта физик һәм юридик затларны күчерү сроклары яки ремонт-тергезелеш эшләре үткәрү кирәклеген тану турында боерык чыгара.»;

л) 4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Теләче муниципаль районы башкарма комитеты әлеге Нигезләмәнең 4.8 пунктында каралган карарны кабул иткән көннән алып 5 көн эчендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, шул исәптән Бердәм порталны яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын (ул булганда) кулланып, язма яки электрон рәвештә җибәрә, комиссия борыгының 1 экземпляры һәм нәтиҗәсе бәяләмәсен гариза бирүчегә җибәрә, шулай ук торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану очрагында мондый бина яки йорт урнашкан урын буенча Дәүләт торак күзәтчелеге (муниципаль торак контроле) органына. Торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр ачыкланган очракта, яшәү тирәлеге факторларының кеше гомере һәм сәламәтлеге өчен аеруча куркыныч тудыра торган зарарлы йогынтысы булу сәбәпле, йә авария хәлендә булу сәбәпле яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган, Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча Нигезләмәнең 36 пунктында каралган нигезләрдә бинаның җимерелү куркынычы булган очракта, әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында каралган карар тиешле федераль башкарма хакимият органына, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органына, җирле үзидарә органына, торак милекчесенә һәм мөрәҗәгать итүчегә карар рәсмиләштерелгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә. Күпфатирлы йортны (андагы торак урыннарны яшәү өчен яраксыз дип таныган очракта) аны файдалануга кертү турында рөхсәт бирелгән көннән алып 5 ел эчендә стихияле бәла-казаларга һәм башка сәбәпләргә бәйле булмаган сәбәпләр буенча авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип танылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында каралган карар, Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кабул итү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, 5 көн эчендә прокуратура органнарына җибәрелә.»;

м) Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 4.10-4.13 пунктлар белән тулыландырырга:

«4.10. Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану яки бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турындагы карар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 56 пунктында күрсәтелгән тиешле гаризаны һәм башка документларны карау нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан гариза бирелгән көннән соң 45 календарь көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4.11. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану турында карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган 3 номерлы кушымта нигезендә шундый карар җибәрә. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәктә шәхсән үзе алу ысулын сайлаган очракта, мондый карар әлеге пунктта күрсәтелгән срокта күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

4.12. Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турындагы карарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 61 пунктында каралган тиешле нигезләмәләргә мәҗбүри сылтама белән баш тарту өчен нигез булырга тиеш.

4.13. Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турындагы карар гариза бирүчегә мондый карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә юллана һәм аңа суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин